КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 20 июль г.Казань № б-1369

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 22 декабрь, б-3564 нче боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 19 февраль, б-318 нче; 2019 ел, 28 декабрь, б-3525 нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган җил электр станцияләре төзү проектын тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан И.Э.Фәйзуллинны, А.Ш.Хөсәеновны чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

«НоваВинд» акционерлык җәмгыятенең девелопмент һәм җил электр станцияләрен технологик тоташтыру идарәсе башлыгы Владислав Иванович Бесчастныйны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары Илгизәр Наил улы Зариповны;

Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Марат Фәйзрахман улы Миңнебаевны;

Татарстан Республикасының Буа муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Фәнис Фариз улы Мифтаховны (килешү буенча);

«НоваВинд» акционерлык җәмгыяте генераль директорының җил паркларының тормыш циклын тәэмин итү буенча урынбасары Андрей Петрович Нестерукны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Ришат Рәшит улы Хәбиповны;

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Фәрит Мөдәррис улы Хәнифовны;

«НоваВинд» акционерлык җәмгыятенең территориаль планлаштыру һәм җир ресурсларын рәсмиләштерү бүлеге башлыгы Милан Алексеевич Цицилинны (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин